# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 2** **18 ноябрь 2024 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче
Карамалы-Елга авылында 2025 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга авылында гражданнар җыены

## КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Туйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, , гаилә әгъзалары мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гаиләләр, ирекле хезмәткәрләр, контракт буенча хәрби хезмәткәрләр Россия Федерациясе Коралллы Көчләренә махсус хәрби операциядә катнашучылдан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (Бер мең) сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 500 (Биш йөз ) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Карамалы Елга торак пункты территориясен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту, территорияне чүп үләннәрдән чабу һәм чистарту)»;

- Карамалы Елга торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (энергияне саклый торган яктырткычларны һәм урамнарны яктырту лампаларын алмаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү) ремонтлау" ;

- Карамалы Елга торак пунктында Ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (куакларны кисү, экскаватор белән агач төпләрен тарттыру, гербицид сатып алу, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, үләнне чабу-килешү буенча эш өчен түләү)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль

берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлил ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы-Елга ур., Сәйдәшев ур., № 19а йорт янында.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.